**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЙБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422726, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Айбаш авылы, Үзәк ур., 1А

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЙБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422726, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Айбаш, ул. Центральная, 1А

тел./факс 8(84365) 60-7-23, e-mail: Ayb.Vsg@tatar.ru

---

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**29 гыйнвар 2025 ел** **№ 1**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Айбаш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы Карары нигезендә «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында», Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2025 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 23.01.2025 ел, № 33 карары белән, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2025 нче елның 01 нче февраленнән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлегендә 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 9165 сум 37 тиен итеп билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге башкарма комитетының 2025 нче елның 1 нче февраленнән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Айбаш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 31.01.2024 № 1 карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында: http//vysokaya-gora.tatarstan.ru.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Айбаш авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р. Сафиуллин

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге башкарма комитеты 2025 нче елның 29 нчы гыйнварындагы № 1 карарына
1 нче кушымта

2025 нче елның 1 нче февраленнән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе

| Хезмәтләрнең атамасы | Хезмәтләр бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Каберне һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 6068,1 |
| 3. Үлгән кешенең гәүдәсен (мәетен) зиратка ташу | 732,89 |
| 4. Кабер (кабер казу һәм күмү) | 2364,38 |
| Бөтенесе | 9165,37 |

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге башкарма комитеты 2025 нче елның 29 нчы гыйнварындагы № 1 карарына
2 нче кушымта

2025 нче елның 1 нче февраленнән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе

| Хезмәтләрнең атамасы | Хезмәтләр бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү | 329,79 |
| 3. Каберне һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 5738,31 |
| 4. Үлгән кешенең гәүдәсен (мәетен) зиратка ташу | 732,89 |
| 5. Кабер (кабер казу һәм күмү) | 2364,38 |
| Бөтенесе | 9165,37 |